КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 20 декабрь г.Казань № 1652

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советын оештыру турында» 2018 ел, 19 апрель, 269 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советын оештыру турында» 2018 ел, 19 апрель, 269 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 ел, 22 август, 676 нчы; 2020 ел, 17 февраль, 117 нче; 2021 ел, 6 сентябрь, 820 нче; 2022 ел, 4 август, 761 нче, 2023 ел, 23 гыйнвар, 32 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советы турында нигезләмәдә:

2.1 пунктчада «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары» сүзләренә алмаштырырга;

2.6 пунктчада «дәүләт һәм муниципаль хакимиятенең башкарма органнары» сүзләрен «республика башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең җирле үзидарә органнары» сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Татарстан Республикасында кулланучылар хокукларын тәэмин итү һәм яклау мәсьәләләре буенча яраштыру советы составында:

Яраштыру советы составыннан У.А.Брендюревны, Л.Н.Шәйхетдинованы чыгарырга;

Координация советы составына түбәндәгеләрне кертергә:

| | |
|---|---|
| Виниченко Владислав Валентиновичны | Сәламәтлек саклау өлкәсендә күзәтчелек итү федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча территориаль органы җитәкчесен (килешү буенча) |
| Нигъмәтуллина Юлия Рөстәм кызын | «Россия кулланучылар берләшмәсе» Татарстан Республикасында төбәк бүлекчәсе рәисен (килешү буенча); |

Д.С.Романов вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы торак-коммуналь хуҗалыгы өлкәсендә төбәк җәмәгать контроле үзәге» ассоциациясе башкарма директоры (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин